КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 июнь г.Казань № 736

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 ел, 17 июнь, 443 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 06 июнь, 559 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгын игълан итү турында» 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 31 мартындагы 678-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2010 - 2015 елларга «Киләчәк» -

«Будущее» Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясен раслау турында» 2010 ел 30 декабрь, 1125 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 31 декабрь, 1125 нче карары;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең республика стратегиясе турында» 2013 ел, 11 февраль, 90 нчы карары белән расланган 2013 – 2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең республика стратегиясенә теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 06 декабрь, 952 нче карары;»;

уналтынчы абзацта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

унҗиденче абзацта «2020» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта «2020» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм дини һәм милли нигездә низагларны кисәтү системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2015 ел, 25 ноябрь, 892 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 385 нче; 2016 ел, 21 ноябрь, 859 нчы, 2023 ел, 22 май, 625 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм дини һәм милли нигездә низагларны кисәтү системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентына кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3.1. | 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен һәм Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмати-аналитик белешмә әзерләү, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы, | квартал саен, хисап чорыннан соң киләторган айның 5 числосына кадәр | е) Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт программаларының үтәлешен мониторинглау күрсәткечләре»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы, «Халык иҗатына ярдәм. 2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы төп халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру», «2014 - 2025 елларга төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү» ярдәмче программалар өлешендә: программаның үзенең һәм аның чараларының максатчан күрсәткечләренә ирешү турында, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге һәм аларны үзләштерүнең үз вакытында башкарылуы турында мәгълүматны үз эченә ала (уздырылган чаралар саны һәм аларның планлаштырылган чараларга процентлы нисбәте, җәлеп ителгән халыкны колачлау (үткән чор белән чагыштырганда, чараларда катнашучылар, тамашачылар/динамика), планлы һәм фактик финанслау, массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр саны) | | |

16.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «16.1. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икъти- | тапшыру вакыты: хисап | е) Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтен гамәлгә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | садый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру барышы турында мәгълүмати-аналитик белешмә әзерләү, программаның үзенең һәм аның чараларының максатчан күрсәткечләренә ирешү турында, финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге һәм аларны үзләштерүнең үз вакытында башкарылуы турында мәгълүматны үз эченә ала (уздырылган чаралар саны һәм аларның планлаштырылган чараларга процентлы нисбәте, җәлеп ителгән халыкны колачлау (үткән чор белән чагыштырганда, чараларда катнашучылар, тамашачылар/динамика), планлы һәм фактик финанслау, массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр саны) | кварталыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр | ашыруга бәйле дәүләт программаларының үтәлешен мониторинглау күрсәткечләре». |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен раслау турында” 2021 ел, 17 май, 344 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясендә:

стратегия паспортында «Стратегияне финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Стратегияне финанслау күләмнәре | Стратегияне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, |

| | |
|---|---|
| | 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга каралган финанс чаралары исәбеннән башкарыла.<br>Искәрмә. Стратегияне финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле елга һәм план чорына төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук Стратегия чараларын финанслашуга федераль бюджеттан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; |

3.1 пунктта:

кырык тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Милли сәясәт өлкәсендә гамәлгә ашыру механизмнары булып «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү»; «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру»; «Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу»; «2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары тора.»;

алтмыш өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 пунктның егерме беренче абзацында «башкарма хакимият органнары белән,» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары белән,» сүзләренә, «җирле үзидарә» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең беренче абзацында «2014 – 2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 4 июнь, 520 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче, 2023 ел, 16 май, 597 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегиядә:

1.1 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары»;

җиденче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе раслаган 2018 елның 29 сентябрендә» сүзләрен «, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе тарафыннан 2018 елның 29 сентябрендә расланган» сүзләренә алмаштырырга;

8.2 пунктта:

5 пунктчада «2014 – 2024 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктчада «(2020 - 2023 еллар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

12 пунктчада «2014 – 2024 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктчада «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2027 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасы;»;

16 пунктчада «2014 – 2023 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктчада «2014 – 2024 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктчада «2014 – 2024 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

20 пунктчада «2014 – 2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

21 пунктчада «2014 – 2023 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктчада «2014 – 2023 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

24 пунктчада «2015 – 2023 елларга» сүзләрен «2015 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктчада «2015 – 2023 елларга» сүзләрен «2015 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

26 пунктчада «2016 – 2023 елларга» сүзләрен «2016 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктчада «(2018 - 2024 еллар)», «2018 - 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

28 пунктчада «2019 - 2023 елларга» сүзләрен «2019 - 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

30 пунктчада «2019 – 2023 елларга» сүзләрен «2019 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

31 пунктчада «2019 - 2022 елларга» сүзләрен «2019 - 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

32 пунктчада «(2020 - 2025 еллар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел,

20 август 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче, 2023 ел, 13 май, 589 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сенябрь, 821 нче карары белән расланган «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;»;

алтынчы абзацта «2014 – 2025 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин